ТАТАРСТАН ВАРИСЛАР БЕРЛЕГЕ
СОЮЗ НАСЛЕДНИКОВ ТАТАРСТАНА

# «ЭЗТАБАР ЮЛДАШЫ» ПРОГРАММАСЫ

## *(КЕЧЕ ЯШЬТӘГЕ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫБЫЗ ӨЧЕН)*

# ПРОГРАММА «СПУТНИК СЛЕДОПЫТА»

## *(ДЛЯ МЛАДШИХ ШКОЛЬНИКОВ)*




Яшь дус!

Яшь эзтабар буласың килеме синең? Кызыклы, дулкынландыргыч хәлләр белән очрашырга телисеңме? Әлегә син бу искиткеч дөньяның алдында гына торасың. Бер генә адым атлау белән син әйләнә-тирәдәге табигатькә, кешеләргә һәм үзеңә бөтенләй икенче күзлектән карый башларсың.

Эзтабар исеме алгач, көчлерәк, акыллырак, мөстәкыйльрәк була барырсың. Яшьтәшләрең һәм өлкән иптәшләрең арасыннан тугрылыклы дуслар табарсың.

Эзтабар булгач, күп нәрсәне үзең дә үзләштерәчәксең. Табигатьтә дөрес ориентлашырга, кызыклы маршрутны билгеләргә, яңгырлы көндә чыланмый йөрергә, беренче медицина ярдәме күрсәтергә, үзеңә зыян китермичә генә табигать тормышын күзәтергә өйрәнәсең.

Эзтабар булгач, үзең белгән һәммә нәрсәне башкаларга да өйрәтә алачаксың. Чөнки безнең «Һәрвакыт әзер бул!» девизы үзең турында кайгырту һәм мохтаҗларга ярдәм итү турында сөйли. Ә «Һәр көнне игелекле эш башкар!» дигән шигаребез (лозунгыбыз) үзеңнең гаиләңә, дусларыңа, җәмгыятькә файдалы булырга әзер икәнлекне күрсәтә. Синең көндәлек һәр игелекле эшең башкаларның тормышын яхшыртырга ярдәм итә.

Һәм, ниһаять, эзтабар булу — бик кызыклы һәм күңелле шөгыль.

Я, ничек? Чак кына өлкәнрәк булырга телисеңме син? Әгәр шулай икән, бу китапчык сиңа һәм синең дусларыңа бу өлкәдә ярдәм итәчәк.

Шулай итеп, син эзтабар булырга карар кылдың.

# «КӨН САЕН ЯХШЫЛЫК КЫЛ!»

## ЭЗТАБАР БУЛУ ҖИҢЕЛМЕ?

Өлкән иптәшләрең үзләренең бу китапчык тәкъдим иткән эшләрендә һәм уеннарында катнаштырсыннар өчен сиңа җиде яшь тулу шарт. Аннан соң бу оешмага керергә теләүчеләр өчен кирәкле таләпләрне үтәргә кирәк.

Өлкән вожатый сине һәм дусларыңны эзтабарларның кагыйдәләре, символлары һәм билгеләре белән таныштырыр. Аннары вожатый-остазга Вәгъдә биргәннән соң, син оешмага керүне белдерә торган участокка ия булырсың.

## ЭЗТАБАР ВӘГЪДӘСЕ

Мин, . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . яхшы эзтабар булырга һәм эзтабарлар кагыйдәләрен төгәл үтәргә вәгъдә бирәм.

## ЭЗТАБАР КАГЫЙДӘЛӘРЕ

Эзтабар — кыю кеше.

Эзтабар — намуслы кеше.

Эзтабар — кешелекле кеше.

Эзтабар тагын да яхшырак булырга омтыла.

Баштарак эзтабарлар кыюлыкны тирән чокыр аркылы сикерүдә, биек агачка менүдә күрерләр. Ә аннары аларга чын Кыюлыкның ярамаган эшләрең турында курыкмыйча әйтә алуда, дөресен генә сөйләүдә икәнен аңлау килер. Менә шунда алар Намус сүзенең мәгънәсенә төшенерләр — әйтүе җиңел дөреслеккә караганда әйтүе кыен дөреслекнең кадерлерәк булуын белерләр. Ләкин чын эзтабарга Кыю һәм Намуслы булу гына җитми. Ул кешелеклелек хисенә ия булырга — өендә әти-әниләренә һәм якыннарына, урамда танышларына һәм бөтенләй дә таныш булмаганнарга булышырга тиеш. Эзтабар янәшәсендәге барча җиһанга — кешеләргә дә, агачларга да, җәнлек-җанвар, кош-кортларга да рәхәт булсын. Иң әһәмиятлесе — эзтабар бүген кичәгедән яхшырак, иртәгә бүгенгедән яхшырак булырга омтылсын. Үзе теләп тотынса, берничә елдан ул ышанычлы варис, ә киләчәктә — Туган илнең чын гражданины булып үсеп җитәр.

## ЭЗТАБАР ШИГАРЕ (ЛОЗУНГЫ)

Эзтабарның шигаре — «Көн саен яхшылык кыл!» Тыныч кына, мактанмыйча һәм мактау көтмичә эшләнгән һәр файдалы эш — яхшы эш. Көн дә яхшылык эшләү — һәр эзтабар өчен гадәти хәл, иялэнгән яшәү рәвеше.



## БЕЗНЕҢ СИМВОЛЛАР.



Безнең символларның төсе: ак, яшел, кызыл.

Бу символларны син байракта да, отряд флагында да, галстугыңда да күрәсең. Ә һәр төс нәрсәнедер аңлата:

ак — безгә дөрес юлны күрсәтүче төс;

яшел — безнең Җир шарыбыз төсе. Андагы кешеләр тыныч һәм бәхетле яшәргә телиләр;

кызыл — игелеклелек төсе ул, кешеләргә үз җаныңның җылысын өләшүче булган күңелнең бер чаткысы.

Төсле карандашлар яисә фломастерлар белән әлеге галстукны буя.

## ЧЫЛБЫР

Чылбыр — бер яшьтәгерәк биш-сигез баладан торган берләшмә. Ул уртак мавыгуларга, дуслыкка яки тору урынының янәшәлегенә нигезләнеп төзелә. Чылбыр — коллектив, аның көче — бердәмлектә. Чылбыр булып берләшкән бу коллектив бик күңелле яши. Бергә балалар сәяхәтләргә бергәләп әзерләнү һәм бергәләп сәфәр чыгу, бергәләп төрле уеннар уйнау, бергәләп җырлау һәм көлү, өйдәүче-остаз кушканнарны бергәләп эшләүнең тәмен һәм рәхәтен татыйлар.

Алар шулай ук өлкәнрәк балалар — варислар тәкъдим иткән эш һәм шөгыльләрдә дә катнашалар. Варислар эзтабарларга рәсем, кул эшләре конкурслары уздырырга булышалар, үз эшләре турында сөйлиләр, спорт бәйрәмнәре оештыралар.

Һәр чылбыр үзенә-үзе исем таба. Ул, әлбәттә, кызыклы да, яңгыравыклы да, эчтәлекле дә булырга тиеш. Хайван яки кош исеме, яраткан китап персонажы, мультфильм герое — күңелләренә кайсы хуш килә, чылбырдагылар шунысын сайлыйлар.

Чылбырны командир җитәкли. Өйдәүче-остаз белән бергәләп сез арагыздан берәүне, барыгыз да хөрмәт итә торган эзтабарны командир итеп сайлыйсыз. Ике-өч ай узган саен, чылбыр командирын яңадан сайларга мөмкин. Димәк, син дә командир була аласың.

Чылбырның максаты гади һәм ачык — сине һәм дусларыңны шәп сәяхәтчеләр итү, көчле, белемле, тәрбияле кешеләр итү.



# ОТРЯД (ТӨРКЕМ)

Син һәм синең дусларың тагын бер коллектив — отряд эчендә дә яшисез бит әле. Синең отрядка өч, дүрт яки биш чылбыр керергә мөмкин. Бөтен бер отряд — бу инде зур көч һәм ул зур эшләр дә эшли ала. Отряд җыеннарында чылбырлар үзара көч сынашалар, ярышлы, уеннар оештыралар, осталыкларын күрсәтәләр.

Отрядның флагы, ә флагта эмблемасы була. Иң яхшысы, билгеле, флагны үзең уйлап, үзең ясау. Бәлки, сезгә әйдәүче-остаз яки өлкәнрәк яшьтәге варислар ярдәм итәр. Отряд үз флагын кадерләп саклый һәм мөһим эшкә флаг тотып чыга.

# НИЧЕК ЗУР ҮСӘРГӘ

Өлкәннәр еш кына: «Тизрәк үссен иде бу!» — дип кабатлыйлар. Балалар үзләре дә шуны тели дип башларына да килми инде аларның. «Үсәргә! Тизрәк мөстәкыйль булырга»! Өлкәннәргә рәхәт, аларның «дүрт үзем» кагыйдәсе бар:

1. Үзем уйлап табам.
2. Үзем карар кылам.
3. Үзем эшлим.
4. Үзем бәялим.



Без дә үзебез эшлибез: «Үзебез уйлыйбыз, карар кабул итәбез, эшлибез һәм эшебезгә бәя куябыз».

Ә хәзер осталыкка алып баручы сукмактан өч адым атлыйк. Өлкәннәрнең һәркайсы — нинди дә булса бер мөһим эшнең остасы. Өлкәннәр кебек мөстәкыйль рәвештә нык итеп төймә тагу, ватык уенчыкны көйләү яки башка эш эшләү өчен син өч адым ясарга тиеш. Ә алар менә мондый:



1. Минем кебек эшлә.
2. Миннән яхшырак эшлә.
3. Дусларың белән эшлә.

Безнең янга килсәң, без һәммә эшне бергәләп эшләрбез: кечеләр, зурраклар, өлкәннәр. Без барыбыз да тигез, безнең уен һәм эш кагыйдәләребез уртак.



— Барча эшне бергә эшләргә.
— Уйныйсы килгәндә уйнарга.
— Күңелле һәм тату уйнарга; юкка бәхәсләшмәскә, иптәшләр белән ачуланышмаска, рольләрне гадел бүләргә.

Тагын бер киңәш — үскән кеше булу өчен «үзем» сүзе генә җитми. Аның өчен кошлар һәм чәчәкләр тавышын тыңлый белергә, яхшылыкны аңлый белергә, кемнеңдер күңелсезләнеп, арып киткәнен күрә белергә, үзең, дусларың гаиләң, Ватаның турында уйлый белергә кирәк.

Табигать серләрен ачуда, төрле уеннар һәм кызыклар уйлап табуда сине осталарның да остасы итәрлек хикмәтле акылга үсеш баскычлары алып менәр.



# ҮСЕШ БАСКЫЧЛАРЫ




Эзтабар баскычлары сиңа үзеңне сынап карау өчен бихисап мөмкинлек бирәчәк. Бу — белү, өйрәнү юлы. Баскычлар һәркайсы аерым тамга белән билгеләнә, ул тамга киемгә тегеп куела. Баскычлар өчәү «Адымнар», «Башлангыч», «Сукмаклар». Яңа баскычка тырыш хезмәт, яңадан-яңа һөнәр-белем генә күтәрә. Теге яки бу баскыч таләпләренә туры килерлек белем туплагач, син белгәннәреңне җайлы гына итеп тормышта куллана башларсың. Бу сиңа яңа тамга алу өчен генә түгел, ә зуррак максатлар өчен кирәк.



# БЕРЕНЧЕ БАСКЫЧ — «АДЫМНАР»

Шушы баскычка басу һәм ак тамга алу өчен эзтабар чылбырда алты айдан да ким булмаган вакыт яшәргә, түбәндәге белем һәм һөнәрләрен үзләштерергә бурычлы.

1. Эзтабар кагыйдәләрен, девизны һәм шигарьне белү һәм аңлата алу.

2. Үз чылбырың, отрядың, флагың турында сөйли белү, үзара сәламләшү билгесен күрсәтү. Әйдәүче оешманың исемен һәм адресын әйтергә дә була.

3. Йөгереп уйный торган өч уен, туплы өч уен уйный белү, өч бию һәм өч җыр өйрәнү.

4. Үзеңнең спорт күрсәткечләреңне белү (баскан урыннан озынлыкка сикерү, чүгәләү-тору, 60 метрга йөгерү).

5. Киселгәндә яки сыдырылганда, бөҗәкләр тешләгәндә, борыннан кан киткәндә беренче ярдәм күрсәтә белү.

6. Аптечканың кайда торганын белү. Кирәк булганда градусник кую, баш яки эч авыртканда дарулар бирү.

7. Юл йөрү кагыйдәләрен үзләштерү, адашкан очракта нәрсә эшләргә кирәклеген белү.

8. Икедән дә ким булмаган санда яңа һөнәр үзләштерү.

9. Җыеннарны калдырмау, соңарып килмәү. Пөхтә киенеп килү.

10. Әти-әнигә булышырга тырышу. Торган җир турында нинди дә кызык яки гыйбрәт белү.

11. Сынаулар узу, кыюлыкны сынау (мәсәлән, учак аша сикерү) һәм җитезлекне сынау (агачка мену).

# ИКЕНЧЕ БАСКЫЧ «БАШЛАНГЫЧ»



Бер елдан да ким булмаган вакыт буе мәктәптә, җыеннарда активлык күрсәткән, әти-әнисенә ярдәм итеп, тел өйрәнеп булышкан, ак тамгага ия булган һәм түбәндәгеләрне эшли белгән эзтабар яңа баскычка күтәрелә һәм яшел тамга ала:



1. Үз чылбыры һәм отрядының традицияләрен белә, алар турында сөйли ала. Күкрәккә тагыла торган эзтабар тамгасының мәгънәсен белә һәм аңлата ала. Аңа бер эшне ике мәртәбә куелуның кирәге юк.



2. Сикереп уйный торган — биш, йөгереп уйный торган биш уен белә, атып мишеньга тидерә ала яки сикергеч бау белән оста сикерә.

3. Биш җыр һәм биш бию белә.

4. Спорт күрсәткечләрен яхшырта. Идәнгә ятып кулларында ун мәртәбә күтәрелә ала, йөзә белә, сыңар аягында 20 метрны сикереп уза. Үзенең 60, 100 метрга йөгерүдәге, урыннан озынлыкка сикерүдәге, чүгәләү-торудагы күрсәткечләрен исендә тота.

5. Үзе торган җирнең уннан да ким булмаган тор кыргый хайванын (кош, бөҗәк, балык) атап бирә ала.

6. Үзе торган җирдә үсә торган агулы үсемлекләрне аера.

7. Урманда, табигатьтә үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен белә. Сәяхәтләр яки экскурсияләр оештыруның үзе уйлап тапкан төрләрен тәкъдим итә.

8. Үзе торган җирнең истәлекле урыннарын белә, үз шәһәре яки авылының кызыклы кешеләре турында чылбырдагы иптәшләренә аңлата.

9. Кан киткәндә, кул яки аякка сөял чыкканда, җиңелчә пешкән чакта беренче ярдәм күрсәтә ала. Авыру кеше янына врач чакырта белә.

10. Республика флагының нинди икәнен, кайсы төснең нәрсә аңлатканын, флагны нинди очракларда күтәрәләр икәнен белә.

11. Бик тиз киенә һәм чишенә, ос һәм аяк киемнәрен һәрвакыт чиста тота, чәчен пөхтә йөртә.

12. Тәкъдим ителгән оч һөнәрнең берсен, аңа өстәп тагын ике һөнәр өйрәнә.

13. Сынаулар уза: а) эзләүче (мәсәлән, яшерелгән әйберне таба); б) энә тоту остасы (мәсәлән, төймә тага, ямау сала); в) оста кул (мәсәлән, ниндидер модель яки уенчык ясый).



# ӨЧЕНЧЕ БАСКЫЧ «СУКМАКЛАР»

Бу баскычка басу һәм кызыл тамга тагу өчен ике ел эзтабар булып яшәргә һәм түбәндәге һөнәр һәм белемнәрне үзләштерергә кирәк:



1. «Өзелгән чылбырлар», «Дус тап», «Өченче кеше артык», «Котүче», «Чөлән аяк»та йөрү» уеннарының өчесен белү.



2. Үз чылбыры һәм отрядының җырларын, халык җырларын, аеруча үз төбәгендә туган җырларны белү.

3. Тон кунулы сәяхәткә чыгу өчен ниләр кирәген белү, әйберләрне дөрес итеп тутыру.

4. Гади тоен төйнәү, биштәр тутырганда шул тоенне куллану.

5. Сәяхәт өчен зарур булган куркынычсызлык кагыйдәләрен белү.

6. Суда үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен белү, 25 метр араны йөзеп узу.

7. Җәяүле сәяхәт өчен шәхси аптечка тутыру.

8. Кузгә чүп кергәндә, урман бөте (талпан) кадалганда, елан чакканда, очлы әйбердән яра алганда, пешкәндә беренче ярдәм күрсәтә белү.

9. Компасның төзелешен белү, аның нәрсәгә хезмәт итүен аңлата алу.

10. 15 төрле йорт хайванын яки кыргый хайванны (кош) тану, яки эзләрен аера белү.

11. Агулы үсемлекләрне (чәчәк, гөмбә, җиләк) тану, шуларны ашап агуланганда беренче ярдәм күрсәтә белү.

12. Авыл, шәһәр, республика турында кызыклы итеп сөйләү.

13. Үз чылбырындагы балалар белән нәниләргә бүләкләр әзерләү яки ниндидер уен өйрәтү.

14. Тәкъдим ителгән һөнәрләрнең берсен, аңа өстәп тагын ике һөнәр сайлап өйрәнү.

15. Сынаулар узу: а) «Беренче ярдәм» (мәсәлән, борыннан кан килүне туктату); б) «Учак хуҗасы» (мәсәлән, учак өчен урын табу, учакны сүндерү); в) «Коллекционер» (мәсәлән, үзе җыйган коллекцияне күрсәтеп, шул турыда сөйли).